шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәүгә җибәрелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының еллык күләме, әлеге концессия килешүләрен, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шулай ук «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән кире кайтарылмый торган кертемнәрдән тыш, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең күләмен исәпкә алмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең расланган гомуми еллык күләменең 10 процентыннан артырга тиеш түгел.

Татарстан Республикасы агымдагы финанс елында Россия Федерациясе субъектларының бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы булган һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән чыгымнарның күләме, әлеге концессия килешүләрен, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шулай ук «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән кире кайтарылмый торган кертемнәрдән тыш, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең күләмен исәпкә алмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең расланган гомуми еллык күләменең 10 процентыннан артып киткән очракта, Татарстан Республикасы, тиешле яңа йөкләмәләр алмыйча, чираттагы елның 1 гыйнварына кадәр кабул ителгән, концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килгән йөкләмәләрне, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, шулай ук финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен генә башкарырга хокуклы.

Күрсәтелгән чикләү 2025 елның 1 гыйнварына кадәр төзелгән концессия килешүләренә, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләргә, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләренә кагылмый.

Татарстан Республикасы хисап финанс елында Россия Федерациясе субъектларының бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы булган очракта, хисап финанс елында концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, шулай ук финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәүгә җибәрелгән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының күләме Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше хакындагы еллык хисап белешмәләре буенча әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән чикләүгә туры килергә тиеш.»;

3) $23^1$ статьяга түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$. Агымдагы финанс елында муниципаль берәмлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарының чираттагы финанс елында (чираттагы финанс елында һәм план

чорының һәр елында) концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәүгә җибәрелә торган еллык күләме, әлеге концессия килешүләрен, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шулай ук гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмый торган кертемнәр булган чараларны башкаруга кире кайтарылмый торган кертемнәрдән тыш, кире кайтарылмый торган кертемнәр һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән түләүләр күләмен исәпкә алмыйча, җирле бюджет керемнәренең расланган гомуми еллык күләменең 10 процентыннан артырга тиеш түгел.

Агымдагы финанс елында муниципаль берәмлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы муниципаль берәмлекнең чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджетында әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән чыгымнарның күләме, әлеге концессия килешүләрен, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шулай ук гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмый торган кертемнәр булган чараларны башкаруга кире кайтарылмый торган кертемнәрдән тыш, кире кайтарылмый торган кертемнәр һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән түләүләр күләмен исәпкә алмыйча, җирле бюджет керемнәренең расланган гомуми еллык күләменең 10 процентыннан артып киткән очракта, муниципаль берәмлек, тиешле яңа йөкләмәләр алмыйча, чираттагы елның 1 гыйнварына кадәр кабул ителгән, концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килгән йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, шулай ук финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен генә башкарырга хокуклы.

Күрсәтелгән чикләү 2025 елның 1 гыйнварына кадәр төзелгән концессия килешүләренә, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләргә, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләренә кагылмый.

Хисап финанс елында муниципаль берәмлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы муниципаль берәмлек бюджетының хисап финанс елында концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, шулай ук финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү

йөкләмәләрен үтәүгә җибәрелгән чыгымнары күләме җирле бюджет үтәлеше хакындагы еллык хисап белешмәләре буенча әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән чикләүгә туры килергә тиеш.»;

4) 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктлар өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт бурычын реструктуризацияләү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Муниципаль бурычны реструктуризацияләү, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән муниципаль берәмлекләрнең бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы алдындагы бурычын төшереп калдыру нигезләре, шартлары һәм тәртибе билгеләнгән очракта, төп бурычның суммасын өлешчә төшереп калдырып (киметеп) гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

5) 31 статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт бурычының күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләменнән, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, артырга тиеш түгел.

Татарстан Республикасы агымдагы финанс елында Россия Федерациясе субъектларының бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы булган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бурычының күләме, концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрнең гомуми күләмен исәпкә алып, әлеге концессия килешүләрен, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шулай ук «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән кире кайтарылмый торган кертемнәрдән тыш, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләменнән артырга тиеш түгел.

Татарстан Республикасына карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 130 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар гамәлгә ашырылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бурычының күләме, концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәгәндә барлыкка

килә торган йөкләмәләрнең гомуми күләмен исәпкә алып, әлеге концессия килешүләрен, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шулай ук «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән кире кайтарылмый торган кертемнәрдән тыш, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләменең 50 процентыннан артырга тиеш түгел.

Күрсәтелгән чикләү 2025 елның 1 гыйнварына кадәр төзелгән концессия килешүләренә, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләргә, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләренә кагылмый.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән Татарстан Республикасы йөкләмәләренең гомуми күләме озак сроклы чорга Татарстан Республикасы бюджет фаразында чагылдырылырга тиеш.

Татарстан Республикасы хисап финанс елында Россия Федерациясе субъектларының бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы булган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бурычының күләме, концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, шулай ук финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрнең гомуми күләмен исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше хакындагы еллык хисап белешмәләре буенча әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән чикләүләргә туры килергә тиеш.»;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль бурычның күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар белән расланган җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменнән, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең һәм (яисә) физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән түләүләрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, артырга тиеш түгел.

Агымдагы финанс елында муниципаль берәмлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы муниципаль берәмлек өчен муниципаль бурычның күләме, концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрнең гомуми күләмен исәпкә алып, әлеге концессия килешүләрен, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен

финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шулай ук гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмый торган кертемнәр булган чараларны башкаруга кире кайтарылмый торган кертемнәрдән һәм (яисә) физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән түләүләрдән тыш, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар белән расланган җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменнән артырга тиеш түгел.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 пунктында һәм әлеге Кодексның 44 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар гамәлгә ашырылган муниципаль берәмлек өчен муниципаль бурычның күләме, концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрнең гомуми күләмен исәпкә алып, әлеге концессия килешүләрен, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шулай ук гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмый торган кертемнәр булган чараларны башкаруга кире кайтарылмый торган кертемнәрдән һәм (яисә) физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән түләүләрдән тыш, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар белән расланган җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменең 50 процентыннан артырга тиеш түгел.

Күрсәтелгән чикләү 2025 елның 1 гыйнварына кадәр төзелгән концессия килешүләренә, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләргә, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләренә кагылмый.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән муниципаль берәмлек йөкләмәләренең гомуми күләме озак сроклы чорга муниципаль берәмлекнең бюджет фаразында чагылдырылырга тиеш.

Хисап финанс елында муниципаль берәмлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы муниципаль берәмлекнең муниципаль бурычы күләме, концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне, шулай ук финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрнең гомуми күләмен исәпкә алып, җирле бюджет үтәлеше хакындагы еллык хисап белешмәләре буенча

әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән чикләүләргә туры килергә тиеш.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. Әлеге статьяның 4 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында һәм 5 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында каралган йөкләмәләрне исәпләү тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.»;

6) 52[1] статьяның 2 пунктында «гамәлдә булган чорларында» сүзләреннән соң «илкүләм проектларны һәм» сүзләрен өстәргә;

7) 77 статьяның 3 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа ундүртенче абзац өстәргә:

«кичектергесез гуманитар чара күрү, гуманитар ярдәм йөкләрен илтү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү гамәлләрен финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре яңадан бүленгән очракта.»;

б) ундүртенче – унҗиденче абзацларны тиешенчә унбишенче – унсигезенче абзацлар дип санарга;

8) 80[2] статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында «һәм муниципаль ихтыяҗларны» сүзләрен «ихтыяҗларын» сүзенә алмаштырырга;

9) 1 нче кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативы хисаплы дотация күләменең (хисаплы дотация күләме өлешенең) тиешле муниципаль берәмлек территориясе буенча Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле физик затлар керемнәренә бердәй методика нигезендә фаразлана торган салым күләменә нисбәте буларак исәпләнә:

$$N^{i}_{\text{ндфл}} = \frac{\text{РД}^{i}}{\text{НДФЛ}^{i}} \times 100\%,$$

монда:

$N^{i}_{ндфл}$ – $i$-муниципаль берәмлек өчен физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативның исәп-хисап күләме;

$\text{РД}^{i}$ – $i$-муниципаль берәмлек бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан хисаплы дотация күләме (хисаплы дотация күләме өлеше);

$\text{НДФЛ}^{i}$ – чираттагы финанс елына $i$-муниципаль берәмлек буенча Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына физик затлар керемнәренә фаразлана торган салым күләме.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының алтмыш өченче, алтмыш җиденче, алтмыш тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәргә карата физик затлар керемнәренә салым суммасы өлешендә әлеге пункт нигезендә исәпләнә торган физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативына карата физик затлар керемнәренә салымнан керемнәрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен Россия Федерациясе Бюджет

кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының алтмыш өченче, алтмыш җиденче, алтмыш тугызынчы абзацларында билгеләнгән нормативның физик затлар керемнәренә салымнан керемнәрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының дүртенче абзацында билгеләнгән нормативка карата нисбәте буларак билгеләнә торган һәм 0,870588 гә тигез булган туры китерү коэффициенты кулланыла.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының алтмыш дүртенче абзацында күрсәтелгән керемнәргә карата физик затлар керемнәренә салым суммасы өлешендә әлеге пункт нигезендә исәпләнә торган физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативына карата физик затлар керемнәренә салымнан керемнәрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының алтмыш дүртенче абзацында билгеләнгән нормативның физик затлар керемнәренә салымнан керемнәрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының дүртенче абзацында билгеләнгән нормативка карата нисбәте буларак билгеләнә торган һәм 0,717647 гә тигез булган туры китерү коэффициенты кулланыла.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының алтмыш бишенче абзацында күрсәтелгән керемнәргә карата физик затлар керемнәренә салым суммасы өлешендә әлеге пункт нигезендә исәпләнә торган физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативына карата физик затлар керемнәренә салымнан керемнәрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының алтмыш бишенче абзацында билгеләнгән нормативның физик затлар керемнәренә салымнан керемнәрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының дүртенче абзацында билгеләнгән нормативка карата нисбәте буларак билгеләнә торган һәм 0,647059 га тигез булган туры китерү коэффициенты кулланыла.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының алтмыш алтынчы абзацында күрсәтелгән керемнәргә карата физик затлар керемнәренә салым суммасы өлешендә әлеге пункт нигезендә исәпләнә торган физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативына карата физик затлар керемнәренә салымнан керемнәрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының алтмыш алтынчы абзацында билгеләнгән нормативның физик затлар керемнәренә салымнан керемнәрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексының 56 статьясындагы 2 пунктының дүртенче абзацында билгеләнгән нормативка карата нисбәте буларак билгеләнә торган һәм 0,600000 гә тигез булган туры китерү коэффициенты кулланыла.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (II өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), «2026 елның» сүзләрен «2027 елның» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 72 статьясындагы 1 пунктының беренче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш) гамәлдә булуын 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнгән срокта, әмма 2024 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, карый дип билгеләргә.

**4 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 9 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 9 пункты 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23, $23^{1}$, 31 статьялары нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына (2025 елга) бюджетларыннан башлап кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе                                                                                    Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 28 сентябрь
№ 68-ТРЗ